Республика Татарстан
СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» июнь 2020 ел № 20

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын билгеләү турында

2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 10 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маенда 21-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул иткән көннән соң "Саба Таңнары" газетасында биш көннән дә соңга калмыйча бастырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча һәм шәһәр җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р. М. Хәсәнов